# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Штерә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**20 ноябрь 2024 ел** **№ 13**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлегендә Штерә авылында 2024 елның 19, 20 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча уткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Штерә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы; Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау Шакурова урамыннан зиратка кадәр);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторына тәгәрмәчләр сатып алу)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 230 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 125 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 96 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 29 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә Штерә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Штерә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы; Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау Шакурова урамыннан зиратка кадәр);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторына тәгәрмәчләр сатып алу)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет урамы, 30б йорт адресы буенча,интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Рамазанов